**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 4 декабрь № 920

г. Казань

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2015 елгы премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен бирү советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Продукциянең һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты, аларның иминлеген тәэмин итү өлкәсендә шактый зур нәтиҗәләргә ирешкән өчен, шулай ук сыйфат белән идарә итүнең югары нәтиҗәле ысулларын керткән өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2015 елгы премияләрен «Эштәге камиллек» номинациясендә түбәндәгеләргә бирергә:

эшчәнлекләрен җитештерү билгеләнешендәге продукция һәм (яки) халык куллануы товарлары җитештерү өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артык булган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыятенең Тимерчелек заводына (Чаллы шәһәре), «Органик синтез» Казан гавами акционерлык җәмгыятенә (Казан шәһәре), «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыятенә (Түбән Кама шәһәре);

эшчәнлекләрен хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артык булган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – җаваплылыгы чикләнгән «ТаграС-РемСервис» җәмгыятенә (Әлмәт шәһәре), «Бәкер» шифаханәсе һөнәр берлекләренең дәвалау-профилактика учреждениесенә (Лениногорск районы);

эшчәнлекләрен хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә гамәлгә ашыручы, эшләүчеләр саны 250 кешедән артмаган предприятиеләр һәм оешмалар категориясендә – җаваплылыгы чикләнгән «Система-Сервис» идарә итүче компания» җәмгыятенә (Әлмәт шәһәре), «МХ 1» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (Казан шәһәре).

2. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премияләрен бирү советына Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен 2015 елгы премияләре конкурсы лауреатларын һәм дипломантларын бүләкләү тантанасын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков